РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» апреля 2026 ел г. Альметьевск № 06

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының
«Әлмәт шәһәрендә ташландык,
хуҗасыз транспорт чараларын
ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау,
утильләштерү тәртибен раслау турында»
2020 елның 21 августындагы 96 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерүгә, кадрлар үзгәрешләренә бәйле

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәрендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен раслау турында» 2020 елның 21 августындагы 96 номерлы карарына (Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 сентябрендәге 104 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) карарның 1 нче кушымтасының 3 бүлегенең 3.12 пунктындагы икенче абзацында «Казан шәһәре буенча ЭЭМ идарәсе» сүзләрен «Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

2) карарга 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«21» августа 2020 ел № 96
карары белән расланган
2 нче кушымта

Әлмәт шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташланган яисә хуҗасыз транспорт чараларын тикшерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Габдуллин И.А. | - комиссия рәисе, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Гыйрфанов А.М. | - комиссия секретаре, "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Экология һәм төзекләндерү департаменты"муниципаль бюджет |

| | |
|---|---|
| | учреждениесе директоры. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Насыйрҗанов А.С. | - Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының Транспорт һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы; |
| Шәрәфетдинов Р.М. | - "Юл хәрәкәте иминлеге" дәүләт бюджет учреждениесенең Әлмәт шәһәрендәге территориаль идарәсе башлыгы; |
| Сафиуллин Р.С. | - "Шәһәр автомобиль юллары идарәсе" акционер җәмгыяте генераль директоры; |
| Рәхмәтуллин Л.И. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегенең полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) ; |
| Крутов К.С. | - Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисе (килешү буенча); |

Килештерү комиссиясе составына күпфатирлы йорт белән идарә итүнең сайланган ысулына бәйле рәвештә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары белән вәкаләт бирелгән зат (күпфатирлы йорт белән урыннар милекчеләре турыдан-туры идарә иткәндә) торак милекчеләре ширкәтенең (торак кооперативының, башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативының, идарәче оешманың) вәкиле, шулай ук күпфатирлы йорт советы рәисе, йорт буенча өлкән (алар булса) кертелергә мөмкин.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары И.Ә. Габдуллинга йөкләргә

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.Р. Фәсхетдинов

Р.05-12060/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА
ИНН 1644035830
КПП 164401001
ОГРН 1051605067183